## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең Иске Тәрбит торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**20 ноябрь , 2020 ел.** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 17 ноябрендә 10 сәгатьтә, 2020 елның 17 ноябрендә 12 сәгатьтә, 2020 елның 18 ноябрендә 10 сәгатьтә, 2020 елның 18 ноябрендә 12 сәгатьтә, 2020 елның 20 ноябрендә 10 сәгатьтә, 2020 елның 20 ноябрендә 12 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

- урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

- су башнясын лицензияләү буенча түләү(су белән тәэмин итү чыганагы буларак артскважинаны санитар-эпидемиологик бәяләмә һәм куллануга кирәкле башка документлар белән рәсмиләштерү).;

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

- җирлектәге торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

- җирлек әһәмиятендәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту;

- җирлек әһәмиятендәге юлларны җәйге чорда үләннәрдән чабу;

- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге башкарма комитетына, экономия барлыкка килгән очракта, җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 291 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -152, бу 53 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 152 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең Иске Тәрбит торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме

- урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;
- су башнясын лицензияләү буенча түләү(су белән тәэмин итү чыганагы буларак артскважинаны санитар-эпидемиологик бәяләмә һәм куллануга кирәкле башка документлар белән рәсмиләштерү).;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлектәге торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- җирлек әһәмиятендәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту;
- җирлек әһәмиятендәге юлларны җәйге чорда үләннәрдән чабу;
- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү,

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге башкарма комитетына, экономия барлыкка килгән очракта, җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске-Тәрбит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Иске-Тәрбит авыл җирлеге Башлыгы В.Г.Тимофеев